ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 539-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.Г. Садриев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 539-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2404-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
К.Г. Садриев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ пунктлар өстәргә:

«$6^1$) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урамнар-юллар челтәрендә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фотога һәм киногa төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган стационар махсус техник чаралар, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фотога һәм киногa төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган күчмә махсус техник чаралар һәм (яисә) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фотога һәм киногa төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган мобиль махсус техник чаралар (алга таба тиешенчә – стационар теркәү чарасы, күчмә теркәү чарасы, мобиль теркәү чарасы) урнаштыру (куллану) турында карар кабул итү;

$6^2$) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урамнар-юллар челтәрендә урнаштырылган һәм (яисә) кулланыла торган, сүндерергә һәм (яисә) сүтеп алырга тәкъдим ителгән стационар теркәү чараларын, күчмә теркәү чараларын, мобиль теркәү чараларын сүндерү турында (кулланмау хакында) һәм (яисә) сүтеп алу турында карар кабул итү;

$6^3$) стационар теркәү чараларын, күчмә теркәү чараларын, мобиль теркәү чараларын урнаштыру (куллану) турында, сүндерү хакында (кулланмау турында)

һәм (яисә) сүтеп алу хакында карарларны Федераль законның 22[1] статьясы нигезендә килештерү;»;

2) 13[1] статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) түләүле гомуми файдаланудагы региональ әһәмияттәге автомобиль юллары һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен саклау өлешендә.»;

б) 5 өлешнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасы өстәргә:

«в) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен саклау өлешендә;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 маендагы 197-ФЗ номерлы Федераль закон белән автомобиль юлларында һәм урамнар-юллар челтәрендә (алга таба – юллар) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны автомат рәвештә фотога, кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган стационар, күчмә, мобиль махсус техник чаралар (алга таба – теркәү чаралары) урнаштыру (куллану) тәртибе билгеләнде.

Юлларда урнаштырылган һәм (яисә) кулланыла торган теркәү чараларын урнаштыру (куллану) турында, сүндерү хакында (кулланмау турында) һәм (яисә) сүтеп алу хакында карарлар кабул итү вәкаләте, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнарына да бирелде.

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, закон проектында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә вәкаләтле органына тиешле вәкаләтләр бирү тәкъдим ителә.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» хакында Федераль законның 3[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон белән автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) киңәйтелде. Аерым алганда, региональ дәүләт тикшереп торуына (күзәтчелегенә) гомуми файдаланудагы түләүле региональ, муниципальара һәм хосусый автомобиль юллары, мондый юлларның түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен саклау өлешендәге мәҗбүри таләпләр кертелде.

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары, бу юлларның түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары йөргән өчен түләү тәртибен саклау муниципаль тикшереп торуга кертелде.

Закон проектында югарыда әйтелгән үзгәрешләрне «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертү карала.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 сентябрендәге 935 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.